СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

23.04.2021 № 9/13

На №__________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы беренче өлеше 20 пункты, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 30-32 статьялары, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2020 елның 24 декабрендәге халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре проекты буенча 2020 елның 24 декабрендәге 1 номерлы халык тыңлаулары беркетмәсе, район уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен расларга.
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлеге Советының 2014 елның 7 августындагы 6/16 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Комсомолец авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен барлык үзгәрешләре белән гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев